**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 5 нче сыйныф**

**Максималь балл – 40 балл**

**I. Тәкъдим ителгән сорауларга 2-3 җөмлә белән генә җавап языгыз (24 балл).**

1. “Аю белән Төлке” әсәре нинди жанрга карый? (**Әкият**) *3 балл*
2. “Аю белән Төлке” әсәрендә конфликт кемнәр арасында туа? (**Аю белән Төлке арасында туа**). *3 балл*
3. “Аю белән Төлке” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**Дусларны белеп, сынап сайларга кирәк, дус дошманнан да хәтәррәк булырга мөмкин һ.б.**) *5 балл*
4. Төлке һәм Аю образлары артына кешеләр холкына хас нинди сыйфатлар яшеренгән? (**Беркатлылык, ышану, хәйләкәрлек, ялган һ.б.**) *5 балл*

5*. Аю һәм Төлке образлары образларның кайсы төренә карый? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Аллегорик образлар, алар аша кеше холкына хас сыйфатлар күрсәтелә**.) *8 балл*

**II. Шигъри әсәр белән эш (16 балл).**

Төн буенча, туктамастан, тышта ап-ак кар ява,
Капланып кырлар, болыннар, җир йөзе ап-аклана.

Ниндәен тиз үзгәреш бу? Ниндәен тиз алмашу!
Арба урнында бу көн кошлар кебек чана чаба.

Күрмәссең тышта яланбаш һәм яланөс бер кеше,
Чөнки тыш салкын-суык, – аннан адәмнәр саклана.

“Кыш та җитте! Нишләек, кайда барыйк?” – дип, кош вә корт
Кайгыра да кайгыра, кышкы суыктан зарлана.

Зарлана кош-корт, вәләкин шулвакыт бер яшь бала,
Йокысыннан уянып, тышка таба күзне сала.

“Кар явадыр! Кыш була!” – дип кычкыра ул яшь бала;
Үз-үзен белми куана, кул чаба да шатлана (*Н.Думави “Беренче кар”*).

1. Әлеге шигырьдән рифмалашып килгән сүзләрне табып языгыз (**ап-аклана, чаба, саклана, зарлана, сала, бала, шатлана**). *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, сынландыру, инверсия, риторик сорау, риторик өндәү, чагыштыру**). *5 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) 5 *балл*

4. Кыш килүгә бәйле бала күңелендә нинди хис уяна? (**Шатлык хисе**) *3 балл*

\

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар**
**(мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 40 балл**

**I. Тәкъдим ителгән сорауларга <u>2-3 җөмлә</u> белән генә җавап языгыз (24 балл).**

1. Г.Ибраһимовның “Алмачуар” әсәре нинди жанрга карый? (**Хикәя**) *3 балл*

2. “Алмачуар” әсәрендә төп конфликтны билгеләп языгыз (**Балачак хыялы белән тормыштагы гаделсезлек арасында яки хыял белән чынбарлык арасында**) *3 балл*

3. “Алмачуар” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**Һәр кеше үзе күргән, кичергән хәлләр, вакыйгалар аша чыныга һ.б.**) *5 балл*

4. Әсәрдә татар халкына хас нинди йолалар, традицияләр сурәтләнә? (**Сабантуй, көрәш, ат чабышы, татар гаиләсе, татар авылы тормышы һ.б.**) *5 балл*

5*. Алмачуар үлеменә Г.Ибраһимов нинди мәгънә сала, аның аркылы нинди сыйфатның юкка чыгуын җиткерергә тели? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Балачак хыялының үлемен, юкка чыгуын җиткерә**). *8 балл*

**II. Шигъри әсәр белән эш (16 балл).**

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям жаным-тәнем белән.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәдне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем. (*Г.Тукай “Туган авыл”*).

1. Әлеге шигырьдән рифмалашып килгән сүзләрне табып языгыз (**авыл / ул, беләм / белән, туган / укыган / торган, күргәннәрем / сөргәннәрем / йөргәннәрем, күрем / тәкъдирем / җирем**). *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, метафора, инверсия һ.б.**). *5 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) *5 балл*

4. Бала күңелендә туган авылына бәйле нинди хис уяна? (**Соклану / горурлык**) *3 балл*

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 7 нче сыйныф

**Максималь балл – 50 балл**

**I. Тәкъдим ителгән сорауларга <u>2-3 җөмлә</u> белән генә җавап языгыз (25 балл).**

1. Ш.Камалның “Акчарлаклар” әсәре нинди жанрга карый? (**Повесть**) *3 балл*

2. “Акчарлаклар” әсәрендә төп конфликтны билгеләп языгыз (**Эшчеләр һәм промысел хуҗалары, тормыштагы, җәмгыятьтәге гаделсезлек арасында һ.б.**) *3 балл*

3. “Акчарлаклар” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**Эшчеләр бәхет эзләп туган җирләреннән читкә чыгып китә, әмма тормыштагы гаделсезлекләр аларга үз хыялларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми һ.б.**) *5 балл*

4. Диңгез һәм акчарлаклар образларына язучы нинди мәгънә сала? (**Алар җәмгыять, тормыш, яшәеш һәм бәхет эзләгән эшчеләрне символлаштыра**) 6 *балл*

5*. Диңгез һәм акчарлаклар образлары образның кайсы төренә карый? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Символик образлар, шартлы төстә яшерен мәгънәне җиткерәләр һ.б.**) *8 балл*

II. **Шигъри әсәр белән эш (25 балл).**

Тәгәрәп-аунап
Буй үскән
Туган илем, исән бул!
Чәч кузгатып,
Җай искән
Таңгы җилем, исән бул!
Йөгреп-йөгреп
Туктаган...
Яулык болгап
Сыктаган
Нәзкәй билем, исән бул! (*Дәрдемәнд “Видагъ”*).

1. Әлеге шигырьдән рифмалашып килгән сүзләрне табып языгыз (**үскән / искән, туктаган / сыктаган**). *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, кабатлау, инверсия, сынландыру, риторик эндәш һ.б.**). *6 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) *5 балл*

4. Аерылуга бәйле шигырьдә нинди хис туа? (**Сагыш**) *3 балл*

5*. Шигырьдә кабатланган сүзләрне табыгыз, шагыйрь ни өчен кабатлый? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (***Исән бул* сүзләрен кабатлый, аның аркылы сагыш хисен көчәйтә, аерылса да, туган ягын онытмаячагын искәртә һ.б.**) *8 балл*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50 балл**

I. **Тәкъдим ителгән сорауларга <u>2-3 җөмлә</u> белән генә җавап языгыз (25 балл).**

1. Ш.Камалның “Буранда” әсәре нинди жанрга карый? (**Хикәя**) *3 балл*

2. “Буранда” әсәрендә төп конфликтны билгеләп языгыз (**Ана һәм бала / Мостафаның эчке каршылыгы**) *3 балл*

3. “Буранда” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**Бала өчен иң кадерле кеше – әни. Аналарны исән чакта зурларга, олыларга, кадерләргә кирәк, соңга калып, үкенергә мөмкин һ.б.**) *5 балл*

4. Буран образына язучы нинди мәгънәләр сала? (**Мостафаның эчке дөньясында барган уй-фикерләр дулкынын символлаштыра**) *6 балл*

5*. Буран, җил образлары образның кайсы төренә карый? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Символик образлар, шартлы төстә яшерен мәгънәне җиткерәләр һ.б.**) *8 балл*

## II. Шигъри әсәр белән эш (25 балл).

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;
Ул – рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең:
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага! (*Г.Тукай “Таян Аллага”*).

1. Әлеге шигырьдән рифмалашып килгән сүзләрне табып языгыз (**Бала / Аллага, юл / ул, кермәгән / күрмәгән, каршына / гаршенә**). *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, метафора, инверсия, риторик эндәш һ.б.**). *6 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) *5 балл*

4. Шигырьдә нинди хис сурәтләнә? (**Соклану**) *3 балл*

5*. *Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең* юлларында фәрештә образына шагыйрь нинди мәгънәләр салган? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Фәрештә образы аркылы баланың күңел чисталыгын, сафлыгын, гөнаһсызлыгын җиткерә**). *8 балл*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 50 балл**

## I. Тәкъдим ителгән сорауларга 2-3 җөмлә белән генә җавап языгыз (25 балл).

1. Ф.Әмирханның “Хәят” әсәре нинди жанрга  һәм кайсы әдәби төргә карый? (**Повесть, эпик төр / проза**) *4 балл*

2. “Хәят” әсәрендә төп каршылыкларны билгеләп языгыз (**дини, милли карашлар арасында / Хәятнең эчке каршылыгы**) *2 балл*

3. “Хәят” әсәрендә төп проблемаларны билгеләп языгыз (**хатын-кыз азатлыгы, җәмгыятьтәге карашларның чикләнгәнлеге, татар тормышындагы тар карашлар һ.б.**) *3 балл*

4. “Хәят” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**бәхеткә ирешү өчен хатын-кызның азат булуы шарт, ләкин моның өчен татар тормышын алга җибәрү кирәк һ.б.**) *5 балл*

5. Бакчада сайраган кош образы образның кайсы төренә карый? (**символик образлар**) *5 балл*

6*. Бакча һәм анда сайраган кош образларына язучы нинди мәгънәләр сала? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Алар мөнәсәбәтләрнең гүзәллеген,  мәхәббәтнең матурлыгын, әмма якында гына булса да ирешү мөмкинлекләре чикле булуны, Хәятнең күңел матурлыгын символлаштырып килә.**) *6 балл*

## II. Шигъри әсәр белән эш (25 балл).

Үлемнәр чикләми,
Чикләми гомерне –
Гомерләр үзләре
Чиклиләр үлемне.

Каеннар булсаң иде,
Бәсәреп тә,
Яшәреп тә,
Мәңге ак торсаң иде.

Каеннар булсаң иде,
Я җирем дип,
Я җырым дип,
Давылда купсаң иде.

Каеннар булсаң иде,

Җил иссә дә,
Уй төшсә дә,
Тик шулай торсаң иде.

Каеннар булсаң иде,
Юлларның да,
Чорларның да
Чатында торсаң иде.
Каеннар булсаң иде. (*М.Әгъләмов “Каеннар булсаң иде”*).

1. Әлеге шигырьнең нинди үлчәм белән язылганлыгын, ритмның нинди үлчәмгә корылуын билгеләгез (**4/7 үлчәменә корылып язылган**) *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, метафора, символ, инверсия һ.б.**). *6 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) *5 балл*

4. Шигырьдә нинди хис сурәтләнә? (**сагыш хисе**) *3 балл*

5*. *Каен* образына шагыйрь нинди мәгънәләр салган? Халык авыз иҗатыннан кулланылып килгән образны нинди яңа мәгънә белән баеткан?Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Каен образы кешеләрне, аларның киләчәккә якты өметләрен, теләкләрен, омтылышларын символлаштырып килә**) *8 балл*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар**
**(мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 10 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 50 балл**

**I. Тәкъдим ителгән сорауларга 2-3 җөмлә белән генә җавап языгыз (25 балл).**

1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре нинди жанрга һәм кайсы әдәби төргә карый? (**Лиро-эпик төр, поэма / кыйсса**) *4 балл*

2. “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә төп каршылыкны билгеләп языгыз (**Йосыф белән агалары арасында**) *2 балл*

3. “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә төп проблемаларны билгеләп языгыз (**Көнчелек, әхлаксызлык, сабырсызлык, үч алу, туганлыкның кадерен белмәү, эгоистлык һ.б.**) *3 балл*

4. “Кыйссаи Йосыф” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**Сабыр, әхлаклы, иманлы кеше бәхеткә ирешә ала, яманлык кылганнарны да кичерә белергә кирәк һ.б.**) *5 балл*

5. Төш, кое образлары образның кайсы төренә карый? (**Символик образлар**) *5 балл*

6*. Төш образына язучы нинди мәгънәләр сала? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Төшләр аркылы Кол Гали геройларның киләчәк язмышларын аңлата, әсәр сюжетына метафора булып килә**) *6 балл*

## II. Шигъри әсәр белән эш (25 балл).

Аерылганда миңа йөрәк дустым
Бүләк итте ефәк яулыгын;
Мин ярама яптым ул яулыкны
Басар өчен агышын канымның.

Кан табыннан куе кызыл төстә
Яулык минем йөрәк турында,
Сөйли миңа аның җылы назы
Һәм ялкынлы сөюе турында.

Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та,
Батырларча алга атладым.
Яулык шаһит: сине һәм илемне
Йөрәк каным белән сакладым. (*М.Җәлил "Яулык"*).

1. Әлеге шигырьнең нинди үлчәм белән язылганлыгын, ритмның нинди үлчәмгә корылуын билгеләгез (**10/9 үлчәменә корылган**). *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, метафора, инверсия һ.б.**). *6 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) *5 балл*

4. Шигырьдә нинди хис сурәтләнә? (**сагыш**) *3 балл*

5*. *Яулык* образына шагыйрь нинди мәгънәләр салган? Халык авыз иҗатыннан кулланылып килгән образны нинди яңа мәгънә белән баеткан?Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Яулык шигырьдә мәхәббәт билгесе итеп күрсәтелә. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә сөйгән ярга мәхәббәт билгесе булса, монда илгә булган мәхәббәт тә өстәлә. Яулык аркылы шагыйрь сөйгәненнән аерылуга бәйле туган сагыш хисен дә сурәтли**) *8 балл*

## Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (мәктәп туры, 2020-2021 уку елы) 11 нче сыйныф

**Максималь балл – 50 балл**

## I. Тәкъдим ителгән сорауларга <u>2-3 җөмлә</u> белән генә җавап языгыз (25 балл).

1. Ә.Еникинең “Матурлык” әсәре нинди жанрга һәм кайсы әдәби төргә карый? (**Хикәя, проза / эпик төр**) *4 балл*

2. “Матурлык” әсәрендә төп каршылыкны билгеләп языгыз (**Хикәяләүченең эчке каршылыгы**) *2 балл*

3. “Матурлык” әсәрендә төп проблемаларны билгеләп языгыз (**Әхлак, эчке матурлык, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, Ана һәм бала** һ.б.) *3 балл*

4. “Матурлык” әсәре аркылы автор нәрсә әйтергә тели? (**Иң мөһиме – эчке матурлык, Ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы** һ.б.) *5 балл*

5. Скрипка образы образның кайсы төренә карый? (**Символик образ**) *5 балл*

6*. Скрипка көе образына язучы нинди мәгънәләр сала? Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Бәдринең әнисенә булган матур мөнәсәбәтен, мәхәббәтен символлаштыра, хикәяләүченең күңел кылларын тибрәтүен дә күрсәтә**) *6 балл*

## II. Шигъри әсәр белән эш (25 балл).

Өзелеп төште бер гөл сабагыннан
Төньягыннан искән җил белән.
Озакламый җилнең канатына
Төялешеп карлар килделәр.

Мамык карлар гөлгә кәфен булды,
Кабер булды бакча түтәле,
Шунда үскән ялгыз бер ак каен
Кабер ташы ролен үтәде.

Кар бураны яңа корбан эзләп
Бөтерелә койма буенда.
Гөл уянмас татлы йокы белән
Изелеп йоклый җирнең куенында.

Тик яз килгәч, гөлнең каберенә
Яңгыр явар, уйнар яшеннәр,
Һәм, түтәлне тутырып, таң алдыннан
Чәчәк атар яңа яшь гөлләр.

Сулган гөл күк, мин дә кышны көтәм,
Йоклар өчен ябынып юрганын.

Күңелегездә көлеп чәчәк атар
Минем соңгы йөрәк җырларым.. (*М.Җәлил “Гөл кабере”*).

1. Әлеге шигырьнең нинди үлчәм белән язылганлыгын, ритмның нинди үлчәмгә корылуын билгеләгез (**10/9 үлчәме белән**). *3 балл*

2. Шигырьдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын табып, мисалларын күрсәтеп языгыз (**эпитет, метафора, чагыштыру, инверсия һ.б.**). *6 балл*

3. Шигырь кем исеменнән сөйләнелә? (**Лирик герой / лирик мин**) *5 балл*

4. Шигырьдә нинди хис сурәтләнә? (**Сагыш хисе**) *3 балл*

5*. *Гөл* образына шагыйрь нинди мәгънәләр салган? Халык авыз иҗатыннан кулланылып килгән образны нинди яңа мәгънә белән баеткан?Ничек дип уйлыйсың? Аңлатып яз. (**Иленә, иҗатка гашыйк шагыйрь, иҗат, шигъри әсәрләр, укучы күңелендә шагыйрь иҗаты уяткан матурлык һ.б.**) *8 балл*